**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 30 июнь № 476

г. Казань

Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннар бирү турында гаризаларын наемга бирүчеләр тарафыннан исәпкә алу тәртибен раслау хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының $91^{14}$ статьясындагы 5 өлеш, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 ел, 16 март, ТРЗ-13 нче Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 нче пункт нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннар бирү турында гаризаларын наемга бирүчеләр тарафыннан исәпкә алу тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\476.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 30 июнь, 476 нчы
карары белән расланды

Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннар бирү турында гаризаларын наемга бирүчеләр тарафыннан исәпкә алу тәртибе

1. Әлеге Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннар бирү турында гаризаларын наемга бирүчеләр тарафыннан исәпкә алу тәртибе Россия Федерациясе Торак кодексының $91^{14}$ статьясындагы 5 өлеш, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 ел, 16 март, ТРЗ-13 нче Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 нче пункт нигезендә эшләнде һәм, гражданнар социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирү турында гаризаларын тапшырганда (алга таба – гариза), гражданнар (физик затлар) һәм социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наемга бирүчеләр арасында барлыкка килүче мөнәсәбәтләрне җайга сала.

2. Гариза бирү хокукына социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗлар исәбенә алынган гражданнар ия.

3. Әлеге Тәртип кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, әлеге органнар вәкаләтләр биргән оешмалар яки Россия Федерациясе Торак кодексының $91^2$ статьясындагы 1 өлешнең 2 нче пунктында күрсәтелгән һәм әлеге органнар тарафыннан төзелгән оешмалар социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наемга бирүчеләр булып тора.

4. Әлеге Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән гражданнар бер социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наемга бирүчегә, шул исәптән муниципаль берәмлек территориясендә төзелә торган социаль файдаланудагы наем йортында, үзләренең сайлавы буенча гариза бирә алалар.

5. Наемга бирүчеләр гражданнар тапшырган гаризаларны, гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗлар исәбенә куйган вакыттан чыгып, чират тәртибендә исәпкә алып баралар.

6. Гражданнарга гаризалар кабул итү мәсьәләләре буенча консультация бирү наемга бирүче хезмәткәре тарафыннан эш вакытында үткәрелә.

Консультацияләр түбәндәге мәсьәләләр буенча бирелә:

гариза бирү өчен кирәкле документлар исемлеге, тапшырыла торган документларның тулы комплекты (җитәрлек булуы) турында;

документларны кабул итү вкыты турында;

гаризаларны кабул итүдә катнашучы вазыйфаи затларның гамәлләренә яки гамәл кылмауларына шикаять бирү тәртибе турында.

Шәхси консультацияләр, язмача консультацияләр һәм телефон аша консультацияләр бирү тәэмин ителә.

Барлык консультацияләр, шулай ук консультация барышында наемга бирүче хезмәткәрләре тарафыннан бирелгән документлар формалары түләүсез була.

Гариза бирүче шәхси консультация алуның ике төрен сайлый ала: гомуми чират режимында яисә язылу буенча (телефон аша).

Консультация бирүне гамәлгә ашыра торган наем бирүче хезмәткәре куелган сорауларга тулы һәм оператив җавап бирү өчен барлык кирәкле чараларны күрергә тиеш.

7. Гариза бирергә теләүче гражданнарны кабул итү, техник мөмкинлек булганда, чират белән идарә итүнең электрон системасы ярдәмендә, алдан телефон аша язылып, техник мөмкинлек булганда, электрон почтаны кулланып яисә гомуми чират режимында алып барыла. Кабул итү вакытын телефон аша билгеләгәндә, наем бирүче хезмәткәре вакытны гариза бирүчеләрне кабул итүнең планлаштырылган вакыты графигы һәм гражданга уңайлы вакыт нигезендә билгели.

8. Кабул итүгә алдан язылганда, граждан үзе турындагы мәгълүматларны, мөрәҗәгать итү сәбәбен һәм теләгән кабул итү вакытын хәбәр итә. Алдан язылу кәгазьдә яки электрон рәвештә алып барыла торган гражданнарны кабул итүгә язу кенәгәсенә мәгълүмат кертү юлы белән башкарыла. Гариза бирүчегә кабул итү көне, вакыты һәм мөрәҗәгать итү өчен бүлмә саны хәбәр ителә.

9. Гариза әлеге Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымта нигезендәге формага ярашлы рәвештә бирелә.

10. Гариза белән бергә наемга бирүчегә түбәндәге документларның күчермәләре тапшырыла:

гариза бирүченең паспорты;

гариза бирүче иренең (хатынының) паспорты (гариза бирүче өйләнгән (кияүгә чыккан) булса);

гариза бирүченең балигъ булган балаларының һәм гариза бирүченең бүтән гаилә әгъзаларының паспортлары (алар гариза бирүче белән бергә яшәгән очракта);

гариза бирүченең балигъ булмаган балаларының туу турында таныклыклары (гариза бирүченең балалары булган очракта);

баланы уллыкка (кызлыкка) алуны билгеләү турында суд карары, әлеге карар кабул ителгән булса (уллыкка (кызлыкка) алучылар баланың туу турында таныклыгына әти-әнисе буларак язылган очраклардан гайре);

опека һәм попечительлек органының опекун яки попечительне билгеләү турындагы акты (гариза бирүчене аның белән яшәгән затларга мөнәсәбәтле опекун яки попечитель итеп билгеләгән очракта);

опека яки попечительлекне гамәлгә ашыру турында шартнамә (гариза бирүче шартнамә буенча аның белән яшәгән затларга мөнәсәбәтле опека яки попечительлекне гамәлгә ашырган очракта);

гариза бирүчене социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗлар исәбенә кую турында карар.

Алда санап үтелгән документларның күчермәләре, гариза бирүче аларның төп нөсхәләрен күрсәткән очракта, наемга бирүче хезмәткәре тарафыннан раслана.

11. Гражданнарны кабул итүне алып бара торган наемга бирүче хезмәткәре түбәндәгеләрне башкара:

гариза бирүче тапшырган документларда күрсәтелгән мәгълүматларның гаризада күрсәтелгән мәгълүматларга туры килүен тикшерүне гамәлгә ашыра;

гаризаларны кабул итүне исәпкә алу журналында, гариза бирүчене кабул итү көнен һәм вакытын, аның элемтә өчен телефонын һәм адресын күрсәтеп, әлеге Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымта нигезендәге формага ярашлы рәвештә гаризаны терки.

12. Гражданга гаризасын кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

гражданны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗлар исәбенә кую турында карар булмау;

гражданның Россия Федерациясе Торак кодексының $91^{17}$ статьясындагы 3 өлешнең 1 нче пункты нигезендә билгеләнгән һәм наемга бирүче тарафыннан торак урыннар бирелергә мөмкин булган гражданнар категориясенә туры килмәве;

наемга бирүченең Россия Федерациясе Торак кодексының $91^{14}$ статьясындагы 3 өлеш нигезендә кабул ителгән карары.

Башка нигезләр буенча гаризаны кабул итүдән баш тарту рөхсәт ителми. Гаризаны бирүдән баш тартуга гариза бирүче законнар белән билгеләнгән тәртиптә шикаять бирә ала.

F:\KARAR\2015\476.doc

Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннар бирү турында гаризаларын наемга бирүчеләр тарафыннан исәпкә алу тәртибенә
1 нче кушымта

______________________________
(наемга бирүче исеме)
______________________________

______________________________
(индекс, почта адресы)
______________________________

адресы буенча яшәүче
______________________________
(Ф.И.А.и.)
______________________________

______________________________
элемтә өчен телефоннары,
______________________________
электрон адресы)

**Гариза**

Миңа, ____________________________________________,
(Ф.И.А.и.)
билгеләнгән мәйдан нормасы нигезендә социаль файдаланудагы торак фондының торак урынына наем шартнамәсе буенча торак урын бирүегезне сорыйм.

Паспорт ____________________________________________
(сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

Гаилә составы:
хатыны (ире) ____________________________________________
(Ф.И.А.и., туган көне)
____________________________________________

балалары: ____________________________________________
(Ф.И.А.и., туган көне)
____________________________________________

____________________________________________

гаиләнең бүтән әгъзалары: ____________________________________________
(туганлык дәрәҗәсе, Ф.И.А.и., туган көне)
____________________________________________

Мин һәм минем гаилә әгъзаларым* әлеге мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын раслыйбыз. Наемга бирүче тарафыннан тапшырылган мәгълүматларга федераль башкарма хакимият органнарында, Федераль салым хезмәтен, Федераль миграция хезмәтен, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтен кертеп, тикшерү үткәрүгә, шулай ук шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгыбызны бирәбез.

Бирелгән мәгълүматлар үзгәргән очракта, үзгәргән мәгълүматларны биш көн эчендә наемга бирүчегә тапшырырга бурычлы булабыз.

«____» ____________ 20___ ел ________________________________________

(гариза бирүче имзасы, Ф.И.А.и.)

«____» ____________ 20___ ел ________________________________________

(балигъ булган гаилә әгъзасы имзасы, Ф.И.А.и.)

«____» ____________ 20___ ел ________________________________________

(балигъ булган гаилә әгъзасы имзасы, Ф.И.А.и.)

«____» ____________ 20___ ел ________________________________________

(балигъ булган гаилә әгъзасы имзасы, Ф.И.А.и.)

«____» ____________ 20___ ел ________________________________________

(балигъ булган гаилә әгъзасы имзасы, Ф.И.А.и.)

«____» ____________ 20___ ел ________________________________________

(балигъ булган гаилә әгъзасы имзасы, Ф.И.А.и.)

Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

| Т/с | Документ исеме | Документның реквизитлары (документның номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән) | Битләр саны | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | |
| 2 | | | | |
| 3 | | | | |
| 4 | | | | |
| 5 | | | | |
| … | | | | |

Гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының имзасын раслыйм.

«____» ____________ 20___ ел ________________________________________

(наемга бирүченең раслаучы хезмәткәре вазыйфасы, имзасы, Ф.И.А.и.)

*Балигъ булмаган һәм (яки) юридик хокуксыз гаилә әгъзалары өчен имза аларның законлы вәкиле тарафыннан куела

Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннар бирү турында гаризаларын наемга бирүчеләр тарафыннан исәпкә алу тәртибенә
2 нче кушымта

Гаризалар кабул итүне исәпкә алу журналы*

| Т/с | Теркәү саны | Гаризаны кабул итү көне һәм вакыты | Гариза бирүченең Ф.И.А.и. | Гариза бирүченең элемтә өчен телефон номеры, индексы, почта адресы, электрон адресы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |

*Журнал буенча тәртип саны документны кабул итү турында бирелгән белешмәнең саны булып тора. Журнал беркетелгән, аңа номер куелган һәм ул наемга бирүче хезмәткәренең мөһере (булган очракта) һәм имзасы белән таныкланган булырга тиеш.

F:\KARAR\2015\476.doc